**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2022 елның « 31 » марты** **834номер**

# КАРАР

**«Юл өслеге җиңеләйтелгән яисә күчеш тибы булган камилләштерелгән автомобиль юлы- кадастр номерлары16:24:160304:539 - 16:24:160304:797 булган җир кишәрлекләренә керү юлы » линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында**

Кадастр номерлары16:24:160304:539 - 16:24:160304:797 булган җир кишәрлекләренә керү юлларын оештыру максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 43, 45, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. «Юл өслеге җиңеләйтелгән яисә күчеш тибы булган камилләштерелгән автомобиль юлы- кадастр номерлары16:24:160304:539 - 16:24:160304:797 булган җир кишәрлекләренә керү юлы » линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләүне башларга.
2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләре нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.
3. Гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2022 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге Карар басылып чыккан вакыттан алып ундүрт көн дәвамында физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына проектны әзерләү тәртибе, сроклары, шулай ук проектның эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.А. Новиков**